**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2770**
**09.06.2020**

Яр Чаллы шәһәре
территориясендә су коену
тыелган су объектларының
исемлеген раслау турында

Су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру, аларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау, шәһәр халкының массакүләм ялы өчен шартлар тудыру максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы карары, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре террриториясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларын шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлар өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2008 елның 25 августындагы 34/14 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә су коену тыелган су объектларының исемлеген расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 9 июнендәге
2770 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә су коену тыелган су объектларының
исемлеге

| Урыннар барлыгы | Су объектлары | Урнашу урыны |
|---|---|---|
| 1 | Мәләкәс елгасы | Мәләкәс урамы, 1 йорт, «Жемчужина» санаторие яны |
| 2 | Мәләкәс елгасы | «Дельфин» бассейны артында |
| 3 | Мәләкәс елгасы | ГЭС поселогы, Үзәк тукталышы |
| 4 | Мәләкәс елгасы | «Кыңгыраулы күпер» |
| 5 | Кама елгасы | йөк порты |
| 6 | Лесное күле | 44 комплекс |
| 7 | Кама елгасы | «Маяк» көймә станциясе районы |
| 8 | Кама елгасы | Навигатор көймә станциясе |
| 9 | Кече Шилнә елгасы | 48 комплекс |
| 10 | Кама елгасы | Ф. Табиев исемендәге Яр буе |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова